КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

17.07.2025 № 106-п

«Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» – «Татарский дух и перо» гомумроссия конкурсын үткәрү турында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2022 елның 13 маендагы 56-п номерлы боерыгы белән расланган Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» – «Татарский дух и перо» гомумроссия конкурсы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендәге 821 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында БОЕРЫК БИРӘМ:

«Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» – «Татарский дух и перо» гомумроссия конкурсын үткәрү турында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2022 елның 13 маендагы 56-п номерлы боерыгы белән расланган Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» – «Татарский дух и перо» гомумроссия конкурсы турында нигезләмәгә («Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2024 елның 14 октябрендәге 204-п номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.7 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

4.3 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

а) конкурс эшләре (3 алып 10 кадәр) (алга таба - конкурс эшләре):

анкетада күрсәтелгән саклау ресурсына сылтама рәвешендә телевизион эшләр (программалар, махсус репортажлар, видеосюжетлар циклы, документаль фильм). Конкурс эшләренә эшнең исеме, авторлары һәм эфирга чыгу датасы күрсәтелгән эфир белешмәсе кушып бирелә. Әлеге белешмә массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесе имзасы һәм мөһере (булган очракта) белән таныкланган булырга тиеш;

анкетада күрсәтелгән саклау ресурсына сылтама рәвешендә радиоэшләр (программалар, махсус репортажлар, радиосюжетлар циклы). Конкурс эшләренә эшнең исеме, авторлары һәм эфирга чыгу датасы күрсәтелгән эфир белешмәсе кушып бирелә. Әлеге белешмә массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесе имзасы һәм мөһере (булган очракта) белән таныкланган булырга тиеш;

басма массакүләм мәгълүмат чараларындагы язмалар (язмалар сериясе, махсус чыгарылышлар), төп нөсхә яки күчермә нөсхә рәвешендә һәм (яисә) сканер аша чыгарылган вариантта тапшырыла. Язмалар массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесе имзасы һәм мөһере (булган очракта) белән таныкланган булырга тиеш;

анкетада күрсәтелгән саклау ресурсына адреслы сылтама күрсәтелеп, интернет басмалардагы язмалар;

анкета-гаризада күрсәтелгән саклау ресурсына сылтама рәвешендә видеороликлар;

анкета-гаризада күрсәтелгән саклау ресурсына сылтама рәвешендә фоторәсемнәр;»

4.3 пунктның «в» пунктчасында:

икенче абзацта «(күчермә)» сүзен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «(күчермә)» сүзен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «(күчермә)» сүзен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «таныклык күчермәсе» сүзләрен «таныклык» сүзенә алмаштырырга;

4.3 пунктның «г» пунктчасында:

икенче абзацта «таныклык күчермәсе» сүзләрен «таныклык» сүзенә алмаштырырга;;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«баш мөхәррирне вазыйфага билгеләп кую турында документ;»;

дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

4.3 пунктның «д» пунктасындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «шәхесне таныклый торган документ һәм редакция таныклыгы яисә журналистның шәхесен һәм вәкаләтләрен раслый торган башка документ»;

4.3 пунктның егерме дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Әлеге пунктның «а» пунктчасында күрсәтелгән эфир белешмәләре һәм басма ММЧ язмалар, әлеге пунктның «б» - «е» пунктчаларында күрсәтелгән документлар, кәгазь документларның электрон рәвешләре буларак, ачык форматта, гамәлдәге программалар белән тәэмин ителгән җайланмалар аша тулысынча яки аерым

өлешләрен карау мөмкинлеге булган килеш, «Татар рухы һәм каләм» – «Татарский дух и перо» гомумроссия конкурсына дип күрсәтеп, konkurs_zozh@mail.ru электрон почта адресына җибәрелә. Бу абзацта күрсәтелгән документлар шифр ярдәмендә яисә эчтәлек белән танышу өчен лицензияле яки башка килешү төзеп, сатып алына торган өстәмә программалар таләп ителә торган башка чаралар ярдәмендә сакланган булырга тиеш түгел. Белешмәләр өчен телефон: 8 (843) 570-31-12.

4.5 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

4.7 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«анкетада күрсәтелгән актив булмаган сылтамалы гариза тапшыру;»;

4.8 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза бирүчегә Конкурста катнашырга рөхсәт бирелмәү турында Агентлыкның җитәкчесе имзалаган һәм анкетада күрсәтелгән электрон почта адресына юлланган хат белән әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктында каралган документлар алынган көннән башлап биш эш көне эчендә хәбәр ителә.»;

4.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.10. Гариза бирүчеләр интеллектуаль милек объектларына барлык хокукларның бары тик Гариза бирүчеләрнеке булуын һәм Агентлык тарафыннан алардан файдалануның интеллектуаль милек турындагы Россия Федерациясе законнарын һәм / яисә өченче затларның хокукларын бозмауны гарантияли.

Конкурста катнашуга гариза биреп, Гариза бирүче Агентлыкның конкурс эшләрендә булган интеллектуаль милек объектларыннан конкурска бәйле максатларда файдалануына ризалыгын белдерә.

Тапшырылган материалга (гаризага) карата өченче затларның нинди дә булса дәгъвалары барлыкка килгән очракта, Гариза бирүче Агентлыкны җәлеп итмичә генә аларны тулы күләмдә (турыдан-туры һәм башка зыяннарны каплауны да кертеп) җайга салырга тиеш.»;

4.11 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

7.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.7. Һәр критерий буенча баллар суммасы буенча конкурс комиссиясе конкурста катнашучылар рейтингын формалаштыра. «Массакүләм мәгълүмат чараларында татар халкының тормышына һәм эшчәнлегенә багышланган иң яхшы эшләр циклы» номинациясендә 1- 4 урыннарга лаек булган катнашучылар, «Социаль челтәрләрдә татар телен һәм мәдәниятен популярлаштыру буенча иң яхшы видеопроект» номинациясендә 1- 3 урыннарга лаек булган катнашучылар җиңүче дип игълан ителә. Теләсә кайсы номинациясендә баллар тигез булганда, призлы урын Конкурс комиссиясе тарафыннан ике яки берничә катнашучыга бирелә. Шулай ук Агентлык номинациядәге әлеге урын өчен бүләкләүгә билгеләнгән акчаларны күрсәтелгән катнашучылар арасында тигез өлешләрдә бүлеп бирә.»;

8.2 пунктта «314 мең сум» сүзләрен «315 тыс. рублей» сүзләренә алмаштырырга;

8.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.3. Конкурста җиңүчеләр чәчәкләр, дипломнар һәм акчалата премияләр белән түбәндәге тәртиптә бүләкләнә:

| № | Номинацияләр | Премияләр саны | Урын | Гомуми сумма<br><br>(мең сум) |
|---|---|---|---|---|
| 1. | «Массакүләм мәгълүмат чараларында татар халкының тормышына һәм эшчәнлегенә багышланган иң яхшы эшләр циклы» | 4 | 1 урын | 60 000 |
| | | | 2 урын | 50 000 |
| | | | 3 урын | 40 000 |
| | | | 4 урын | 15 000 |
| 2. | «Социаль челтәрләрдә татар телен һәм мәдәниятен популярларлаштыру буенча иң яхшы видеопроект» | 3 | 1 урын | 60 000 |
| | | | 2 урын | 50 000 |
| | | | 3 урын | 40 000 |
| Барлыгы | | | | 315 000»; |

1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» – «Татарский дух и перо» гомумроссия конкурсы турында нигезләмәгә
1 нче кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

| Конкурста катнашу өчен анкета-гариза | |
|---|---|
| Гариза бирүче (массакүләм мәгълүмат чаралары исеме; автор*, авторлар коллективы) | |
| Номинация | |
| Конкурс эше | |
| Кыскача эчтәлеге | |
| Эш урнаштырылган саклау ресурсына сылтама | |
| Адрес | |
| Телефон | |
| Электрон почта | |
| Гариза бирүченең банк реквизитлары | |

| | |
|---|---|
| (банка исеме, ИНН и КПП, БИК банка, исәп-хисап счеты счета | |
| ИНН (физик затлар өчен) | |
| СНИЛС (физик затлар өчен) | |

Түбәндәгеләрне раслыйм:

журналистларның «Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» – «Татарский дух и перо» гомумроссия конкурсына җибәрелгән конкурс эшләре өченче затларның авторлык һәм башка хокукларын бозмый.

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормыйм.

* Атасының исеме булган очракта күрсәтелә

** Гариза бирүче авторлар коллективы булган очракта күрсәтелә

Дата ________________

Имза ____________________ ___________________________

(фамилия һәм вазыйфа тулысынча (булган очракта)»

Җитәкче вазыйфасын башкаручы Д.М.Перевезенцев